Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге составындагы Байгол торак пунктында үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2022 елның 23 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенигезендә, 2022 елның 21 ноябрендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципальрайонының Каенлы авыл җирлегенең Байгол торак пунктында үткәрелгән «Гражданнарның үзара салым җыю турындагы" гражданнар җыены буенча кабул ителгән 2021 елның 4 декабренең №2 «Гражданнарның үзара салымга җыелган 145000 сум акчаны китапханә бинасын ремонтлауга, һәйкәлне төзекләндерүгә (шул исәптән һәйкәлне төзекләндерү өчен кирәкле материал һәм әйберләр сатып алуга) юнәлтергә»

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 70 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 38 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 52 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыдагы нәтиҗәләрдән чыгып, гражданнар җыены карары:

1.Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге составындагы Байгол торак пунктында гражданнар җыенын узган дип , гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2022 елның 21 ноябрендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлегенең Байгол торак пунктында үткәрелгән «Гражданнарның үзара салым җыю турындагы" гражданнар җыены буенча кабул ителгән 2021 елның 4 декабренең №2 : "Гражданнарның үзара салымга җыелган 145000 сум акчаны китапханә бинасын ремонтлауга, һәйкәлне төзекләндерүгә (шул исәптән һәйкәлне төзекләндерү өчен кирәкле материал һәм әйберләр сатып алуга) юнәлтергә" дигән карары белән "килешү"(ӘЙЕ), "килешмәү"(ЮК)" карарын- дөрес дип танырга.

3. Мәгълүмат стендларында, Каенлы авыл җирлеге сайтында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлегекарарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каенлы авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Гарипов